**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенә керүче Тарлау торак пунктында Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«22» ноябрь 2022 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2022 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2023 елда Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенә керүче Тарлау торак пункты территориясендә, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына чакырылган гражданнардан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- Тарлау авылында Гафиятуллин урамы буенча юлны асфальтлау».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 60 гражданнар җыенында катнашучылар кертелгән, тавыш бирүдә катнашучылар саны 31 кеше, бу 51,7% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 31 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен халык җыенында катнашучылар 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенә керүче Тарлау торак пунктында гражданнарның җыенын узган һәм аның нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенә керүче Тарлау торак пункты территориясендә, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына чакырылган гражданнардан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- Тарлау авылында Гафиятуллин урамы буенча юлны асфальтлау» - карарын кабул ителгән дип санарга».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Бу карар рәсми игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов